КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 июнь г.Казань № 687

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында» 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 апрель, 234 нче; 2016 ел, 23 июнь, 433 нче; 2016 ел, 14 ноябрь, 840 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1137 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 25 декабрь, 1186 нчы; 2021 ел, 4 ноябрь, 1051 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибендә:

4 пунктта:

беренче абзацта «төзү» сүзеннән соң «(үзгәреш кертү)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) капиталь кертемнәр буенча операцияләрнең факттагы үтәлешен раслый торган документларның таныкланган күчермәләре (үткән чорлар өчен) (Килешүгә үзгәрешләр кертелгәндә).»;

5 пункт үз көчен югалткан дип таныргa;

7 пунктның «д» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның беренче абзацында «10» санын «җиде» сүзенә алмаштырырга;

18 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктның беренче абзаында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктның беренче абзаында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

40 пунктның икенче абзацында татар текстында «Татарстан Республикасы Президенты боерыгы проектын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе боерыгы проектын» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланганалга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүнең бертип формасында:

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктта:

3.5.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Инвестиция проектын тормышка ашыруга ___________________________ ____________________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә өстәлгән кыйммәткә салымсыз капитал кертемнәр (шулардан кимендә 2,5 млн.сумы юридик затны Реестрга керткәннән соң беренче ел дәвамында) җәлеп итәргә, шул исәптән:»;

3.5.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Проектны тормышка ашыру барышында яңа эш урыннары, шул исәптән юридик затны Реестрга керткәннән соң беренче ел дәвамында кимендә 10 (ун) яңа эш урыны булдыруны тәэмин итәргә;»;

3.5.14 пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Резидент түбәндәге преференцияләрне кулланырга хокуклы:

а) федераль бюджетка күчерелә торган оешмалар табышына салым буенча ташламаларны;

б) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган оешмалар табышына салым буенча ташламаларны;

в) оешмалар мөлкәтенә салым буенча ташламаларны;

г) җир салымы буенча ташламаларны;

д) Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына, Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына иминият кертемнәре буенча түбән тарифларны.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Килешүнең 3.6 пунктында күрсәтелгән преференцияләрне бирү, Резидентның бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгында чагылыш тапкан аның эшчәнлегенең фактагы күрсәткечләреннән чыгып, хисап чоры йомгаклары буенча гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин